Республика Татарстан

Глава Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы башлыгы

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

04.09.2024 Менделеевск ш. № 24

2019 елның 16 августындагы 53 номерлы
карары үз көчен югалткан дип тану турында

«Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы турында " 2020 елның 13 мартындагы 10-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә (06.04.2023 елга үзгәрешләр кертеп), Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре территориясендә гражданнар оборонасына җитәкчелекне муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары җитәкчеләре гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә,
КАРАР БИРӘМ:

1. Менделеевск муниципаль районы башлыгының «Менделеевск муниципаль районының Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрдән яклау буенча укыту-консультация пунктлары төзү турында» 2019 елның 16 августындагы 53 номерлы карарын үз көчен югалткан дип санарга.
2. Менделеевск муниципаль районының Гражданнар оборонасы җитәкчесе – Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Р. Искәндәровка 2024 елның 1 сентябренә кадәр Менделеевск муниципаль районының Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрдән саклау буенча уку-консультация пунктлары эшен булдыру һәм оештыру турында карар чыгарырга.
3. Менделеевск муниципаль районының авыл җирлекләре башлыкларына Менделеевск муниципаль районының авыл җирлекләрендә укыту-консультация пунктлары төзү турында элек чыгарылган карарларны (күрсәтмәләрне) гамәлдән чыгаруны тәкъдим итәргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Район башлыгы Р.И. Беляев